Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Сенчел авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 109 «19» июня 2020 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сенчел авыл җирлеге Советының «Сенчел авыл җирлеге территориясендә караучысыз хайваннарны тоту тәртибе һәм йорт хайваннарын тоту Кагыйдәләре турында» 18.05.2015 ел, №12 карары үз көчен югалткан дип тану хакында.

«Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» (2019 елның 27 декабрендәге үзгәрешләр белән) 27.12.2018 ел, №489 Федераль закон, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, тоту һәм караучысыз хайваннарны тоту буенча чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән саклау турында Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 16.11.2019 ел, №82-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сенчел авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сенчел авыл җирлеге Советының «Сенчел авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны тоту тәртибе һәм йорт хайваннарын тоту Кагыйдәләре турында» 18.05. 2015 ел, №12 карары үз көчен югалткан дип санарга .
2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе, Сенчел авыл җирлеге башлыгы ____________ Крайнова И.В.